Фәрит

Вафин





# Кызык китап



Юмор-сатира



# Эчтәлек.


1.  Интернетта белдерү.

2. Табабыз!

3. Кушу һәм алу.

4. Хәтәр дәрес.

5.Рәхмәт!

6. Уртак хисләр.

7.Базар.

8. Эт.

9. Тигез күтәрик.

10. Китәм Кипрга!

11. Яртылы хисап.

12. Күкәй хикмәтләре.

13. Кызыл кар.

14. Сабак.

15. Сабирныкыларны көтәм.

16. Шакир мажаралары

17. Атказану.

18. Көннәрдән беркөнне.

19.Яхшы укытучыга әверелү.

20.Авыл эротикасы.

21.Бәйрәм концерты.

22. Ташлау.

23. Дәрес.

24. Без кемнән ким?

25. Чир.

26. Күтәрелештә.

27.Тәҗрибә җимеше.

28. Әнәскә бар.

29. Барасы килә.

30. Табышмак.




## ИНТЕРНЕТТА БЕЛДЕРУ

***Рәсәйдә яшим.Телләр белмим.Хатын эзлим.Исемем-Бари.Авылда Барилар өчәү,бутамагыз, мине Бөке Бари диләр.Трусиктан төшкән фотоларга гына җавап бирәм.***

**Барига хат.**

Мистер Буки Бари! Хаталырак язам инде,ачуланмагыз. Минем исемем-Элизабет.Нью-Йоркта яшим.Телегез булмаса да, мин риза.Телсез-чукраклар теленә өйрәнү өчен курсларга йөри башладым.Трусигыма төреп фотомны җибәрәм..

**Баридан хат.**

Мисс,Элизабет. Беренчедән,мин-телсез түгел.Икенчедән,ул трусик миңа ни пычагыма,чүплеккә чыгарып аттым мин аны.Үземнең эштә төшкән фотомны җибәрәм.Сулдан җиденчесе-мин.Буки түгел, Бөке Бари.

**Барига хат.**

Кадерле ,Бөке Бари! Фотогызны елый-елый карадым.Туганнарыгыз бик күп икән,җитмәсә барысы бер төсле.Үзем аера алмагач,Брайтон-Бичтагы урыс кафесына алып барып күрсәткән идем,көчкә танып сезне күрсәттеләр.Трусикка атмаска иде, тишелеп беткәндер инде,бер генә кигән идем .

**Баридан хат.**

Элизабет! Район гәҗитендә чыккан фото әле ул бик беләсең килсә.Барысы да фермада үзем үстергән чучкалар.Юкка елап йөрмә,трусигыңны чүплектән эзләп,табып алып кердем.БезнеңМантымаска килеп төшсәң, үзеңә кирәк булуы бар.”Вамин”акча бирми,колбасасын гына ашап торабыз.Купальниктан төшкән фотоңны көтеп калам.Урыс кафеларында бичлар белән бик буталып йөрмә,кара аны,күрмәгәнеңне күрсәтермен.





**Барига хат.**

Кадерлем,Бөке Бари! Купальниктан төшкән фотомны җибәрәм.Мин дә колбаса бик яратам.Ваминыңа әйт,миңа да калдырсын.Ни өчен чит илдән өйләнергә булдың? Үзегездә хатыннар беттеме әллә? Теге күрсәтермен дигән әйбереӊ нәрсә ул бик күрәсе килә.

**Баридан хат.**

Сөеклем,Элизабет! Фотоңны алдым, әрәм булып ятмасын дип Интернетка куйдым.Биш мең бирделәр.Акчамы инде ул.Бөтенләй шәрә булсаң,егерме бишне бирәселәр иде.Түземсезлек белән җавап көтәм.Синең Бариың.Соравыңа җавап бирмәгәнмен икән.Хатыннар бездә буа буарлык. Пычагыма кирәк миңа дуңгыз фермасындагы кочаклап булмаслык акчага тилмереп яткан сасы хатыннар.

**Барига хат.**

Кадерле,Бариюшка! Син фермер да? Бөтен хатыннарны кочаклап чыктыңмыни?

Супер! Әле акча да бирәләрме? Минем дә тизрәк синең кочагыңа керәсем килә башлады.Ах,Бари...

**Баридан хат.**

Саргаеплар беттем бит инде,Элизабетем.Тизрәк Америкага чакыру һәм билетка акча җибәр.

**Барига хат**

Сары белән авырыйсыңмыни? Дәвалан. Мин- бетле түгел.Үзеӊ кочаклап йөргән хатыннардан эзлә бетне.

*Барига хат килү шушы урында туктала.*

Өч көн үткәч Бари тагын белдерү яза.

**Рәсәйдә яшим.Ике тел беләм.Татарча сөйләшәм,урысча сүгенәм.Эчәм,тартам.Эчкәч җырлыйм.Акчам юк һәм булмаячак. Чит илгә күчеп китәргә риза. Өегез каршындагы машина янәшәсендә төшкән фотоларга беренче чиратта җавап бирәм.**






## ТАБАБЫЗ!

— Кер, өйдә, кер. Нәрсә торасың капкадан башыңны сузып торна шикелле.Күбрәк жиффәргәнбез,күрше. Беткән инде, икесе дә беткән. Кайчан калганы бар соң аның. Чит илнекеләр шикелле тәртип белән эчә белмибез. Безгә шул дуңгыз шикелле чөмерергә булсын.Әле ярый, кичә карда ятып калынмаган. Кәкрәеп катар идең. Мунчада йокладым дисеңме? Хәтерлисеңме, теге вакытта аракыны жылытабыздип мунча казанындагы эссе суда шартлаткан идек. Әрәм булмады,кәнишне. Суытып эчеп бетердек. Башны төзәтәбез инде аны төзәтүен. Тик башта табарга кирәк. Кайдан булсын, менә безнең ишек алдында.

Чулак Хәниядән алган яртының пәлтә кесәсендә кайтуын точно хәтерлим. Хатыннан сораган идем, ишек алдына чыгарып аттым ди. Эзлә менә хәзер шуны кар астыннан.

Исеңдәме, үткән ел басудан фермага салам тарттырганда бер ярты югалган иде. Яз көне самый кирәк чагында эскерт астыннан килеп чыкты. Зуррак ләгән алып керәсеңме әллә, күрше? Кара, төнлә күпме кар яуган. Урамга ташырга жайлырак булыр иде дим. Ишек алдыңдагы кар астында бер ярты тилмереп ятканда болай көрәккә таянып торып булмый бит инде. Хәрәкәтләнергә кирәк. Төя әйдә. Вак-вак итеп сал. Урамга чыгып китә күрмәсен кар белән. Кая ташлаган? Белсә-ә-әм! Шул урыннан гына казып алыр идек тә бит. Әйтми, аждаһа! Беләм, беләм, синеке дә жылан. Ачудан Онытмадыңмы, жәй көне кое төзәткәндә бер ярты коега төшеп киткән иде. Суын түгеп бетердек и тәки алып мендек. Эчеп бетергәч кенә кире коега егылып төшкән идең. И күрше, күрде инде безнең башлар бу аракы белән'.Өч кабыргаң сынып, кул-баш сөякләрең чәрдәкләнеп беткән иде бит. Ә үткән кыш балык тотканда бер ярты бәкегә чумган иде. Тәки алып чыктың, ә! Суда батучыларны коткару медале бирерлек кеше бит син,күрше.Үпкәң шешеп өч ай бүлнистә яттың ятуын, ну аракыны су төбендә калдырмадың.

Ә урманда, урманда? Кайсы агач төбенә куйганны онытып ике көн эзләдек, барыбер таптык. Чапкан печән яңгыр астында калып череде инде черүен, зато аракыны үзебез эчтек. Монысын да табарбыз, насыйп булса. Чү, жайлырак көрә. Шушы лапаска кадәр атты микәнни, мәлгунь. Куллар сызлый дигән була тагын. Әйдә, кызурак кыймылда. Күп калмады инде.

Исеңдәме, марига ничек барган идек, ә! Теге, бер матайга утырып кайтканда юлда бер яртыбыз төшеп калган иде. Кире жәяүләп утыз чакрым бардык. И мари авылы башындагы канаудан таптык.

Тукта, хатын чыккан анда, нәрсәдәр лыгырдый. Ә?! Койманың теге ягына бәрдем дисеңме? Чын адәм актыгы икәнсең! Киттек, күрше. Синең ишек алдындагы карны көрибез хәзер. Табабыз булгач, табабыз, табып салабыз инде. Кайчан тапмый калган бар.






## КУШУ ҺӘМ АЛУ.

Көннәрдән беркөнне мәктәпкә фәрман килеп төште. Бөтен дөнья кризис белән мәйханә килгәндә, сез анда ни җаныгыз белән тыныч кына укытып ятасыз, дигәннәр. Өстән килгән һәр боерыкка шундук койрык болгарга өйрәнгән халык киңәшмәгә җыйналды. Сүзне, гадәттәгечә, директор башлады:

— Болай булмый, иптәшләр. Кысарга, кыскартырга кушалар. Кемнән башлыйбыз?

Шуны гына көткәндәй татар теле укытучысы мышкылдап елап җибәрде.

— Татар телен киләсе елдан Мәскәү барыбер укытмаячак, —диде директор. — Аны хәзер үк бетереп куйсак, үзебезгә тынычрак булыр. Шулай бит? Математиканың да кирәге юк. Хәзер бөтенесенең кулында калькулятор, исәпләсеннәр шуның белән. Болай да аңгыра балаларга ялган тарих ниемә хаҗәт? Кыскартабыз! Ә инде җыр белән рәсемгә килсәк, аларны күптән бетерергә вакыт иде.

Директорның күзе артына кнопка кадалган шикелле кыбырсып утырган завучка төште.

— Ә завуч мәсьәләсе болай тора. Кризис чорында кеше дәресен тикшереп йөрү килешмәс. Үз дәресеңне юньләп укытырга кирәк. Анда, әнә, Мәскәүдә Жириновский да ун замының берсен кыскарткан. Бетерәбез завуч штатын һәм вәссәлам!

Дәвам итәбез, хөрмәтле коллегалар! Чиратта физкультура. Кризис котырынганда белем бирми торган фәннәрнең кирәге бармы? Профком моңа ничек карый?

— Моннан да дөрес, моннан да акыллы фикер була алмый, — дип очынып торды профком рәисе. — Тагын шуны өстәп әйтәм: астрономиянең дә кирәге юк. Газеталар йолдызлар фаразы белән тулган. Аннан химия турында да уйлап карасак ничек булыр икән?

— Иллә дә шәп булачак! — диде директор. — Инде ничә тапкыр кабинетны шартлата яздылар. Мәктәпне күккә очырганчы бетерергә кирәк ул химияне.

Директор, тагын нәрсә калды дигәндәй, урындыкларына сеңгән укытучылар өстеннән күз йөгертеп чыкты. Бәрәч, физика укытучысы нишләп тыныч кына утыра анда?

— Тә-әк, физика укытуны да кризис беткәнче туктатып торабыз. Тәгәрмәчнең ничек тәгәрәгәне болай да билгеле, баш катырып утырасы юк. Борчылмагыз, коллегалар! Кризис шулай каты суга инде ул. Шулай итеп, нәрсәләр кала мәктәптә? Урыс телен бөтенләй бетереп булмый, яртысын калдырабыз. Яртысын телевизордан өйрәнерләр. Хезмәткә тими торабыз. Быел җәй малайга өй саласы бар. Тагын бер шәп фикер килде бит әле башка: башлангычларны кушабыз! Беренчеләргә — икенчеләрне, өченчеләргә — дүртенчеләрне. Җитеп торыр. Кризис тирән гәрәк китсә, тагын кыскартырбыз. Каршылар юкмы? Димәк, бер тавыштан! Мин хәзер районга хәбәр итәм. Китми торыгыз.

Бераздан агарынган директор кире әйләнеп керде.— Җәмәгать, — диде ул, дер-дер килеп. - Мине дә кыскартып ташлаганнар бит әле. Өч мәктәпкә бер директор калдырганнар...

# ХӘТӘР ДӘРЕС




Укытучы, мәктәп ишеген ачып, эчкә узды. Гаҗәп хәл: аны берәүдә ишек яңагына кысмады, берәү дә бәреп екмады. Мәхшәр туе булган коридорда сәер тынлык: гөлләр дә идәнгә очып төшмәгән, тәрәзә пәрдәләре дә урынында эленеп тора.. Укучылар чыпчык балалары шикелле чөкердәшеп, матур гына житәкләшеп йөриләр. Киемнәрен күр: концерт куярга килгәннәрмени?

Сүгенү сүзеннән башканы әйтә белмәгән Марат та, авызын ерып, укытучы белән: "Хәерле иртә!" — дип исәнләшеп узып китте. Укытучы, шикләнеп, сыйныф бүлмәсенә керде. Шак-катырлык: аның башына шапылдап такта чүпрәге килеп төшмәде. Идән юылган, такта сөртелгән, хәтта стенага эленгән портретларга кадәр урыннарында. "Исәнмесез!" — дип бердәм исәнләштеләр өндәү билгеләре кебек үрә баскан балалар. Парта астында берәү дә калмаган. Кулыннан рогаткасы төшмәгән Шамил күкрәгенә китабын кыскан, һәммәсе дә гипнозланган кебек укытучының күзләренә карап торалар. Дәрес башланды, һаман тавыш юк, һаман кычкырышмыйлар. Укытучының йөзендә каушау билгеләре күренде. "Юньлегә түгел бу", - дип борчылды ул. Кара әле, арткы партада гел укытучының авызына керердәй булып игътибар белән тыңлыйлар. Ә Наил бөтенләй фәрештәгә әйләнгән. Сагыз чәйнәми, иптәшенә төкерми. "Ярабби,. бетүләрем шушы икән!" — дип уйлады укытучы йөрәгенең чәнчи башлавын тоеп. Дәрес уртасында бәдрәфкә барып тәмәке тартып килә торган Сәлим дә өйрәтелгән эт кебек кымшанмыйча утыра. Наилә бәйләү жепләрен бөтенләй алып килмәгән ахры, кулында каләм, һәрчак ипи күшәп утыра торган Шәүкәтнең авызы шапылдамый. Чебен очкан тавыш та юк. Кинәт шул тынлыкны бозып:

— Булды, Гөлсинә Зәкиевна, төшереп бетердек! — дигән тавыш яңгырады.

Алдынгы тәжрибә конкурсына жибәрәсе дәрес видеотасмага язылып беткән иде.

Марат парта өстенә менеп "Ура-а!" кычкырды. Түшәмгә китаплар, дәфтәрләр очты. Ручка-лар шартлап сынды. Сәлим тәмәкесен алып, бәдрәфкә чапты. Рогатка "пулялары" сызгыра башлады. Укытучының башына кәгазь карга килеп кунды. Ул арада Равил Рәшитнең күз төбенә менеп төште. Кемдер акырып елап жибәрде, артына инә кададылар, ахрысы.

Укытучы: "У-уф!" — дип жиңел сулап куйды...





# РӘХМӘТ .

**(Мәктәп директорына тапшырылмаган хат)**

Рәхмәт, хуҗам, онытмыйсың! Изге зат син, миһербанлы. Берәү булса күптән сызып ташлар иде. Җитте, бу адәм пенсиягә китә, аяк астында буталып йөрмәсен әле дияр иде. Син игътибарлы, шәфкатьле шул. Авылның иң зур урамына агитатор итеп билгеләгәнсең. Шуларны уйлап, йоклый алмыйча боргаланып ятканда, исемеңне еш кабатлыйм. ...Анаңны да искә алам.

Син борчылма. Чаңгы ярышында егылып сынган аяк төзәлеп килә инде. Хәзер йөрергә була. Шундый ышаныч күрсәткәнең өчен чиксез бәхетле мин. Әле узган атнада гына егерме укучының өенә йөреп чыккан идем. Кичә ярминкәдә көне буе товар саттым. Аяклар хәйран язылды. Суыкта кар өеп, сыннар ясау бигрәк тә килеште. Шулай гел йөртеп-йөгертеп торганың өчен Ходай озын гомерләр бирсен сиңа.

Ә дискотекалар өчен аерым зу-у-ур рәхмәт! Шимбә саен клубка чыгып, балаларның чиный-чиный сикерүләрен карап торудан да ләззәтрәк нәрсә юк икән.

Төннәр буе урамда йөргәч, миңа хәзер этләр дә өрмиләр, үз итеп, койрык болгап калалар.

Тикшерүләр килгәндә иң беренче мине искә төшерәсең. Олылыйсың. Ачык дәресләрне яшьләргә үткәрттермәссең бит инде. Алар акчалы эшне генә белә. Районга җыелышларга, семинарларга гел мине генә җибәреп торуыңа да рәхмәт.

Күпме генә мактасам да, рәхмәтләремне әйтеп бетерә алмам кебек. Алар шулкадәр күп, тау кадәр өелгән. Астында калып харап булмагаең дип куркам. Әмма әйтмичә дә ярамый. Шатлык өстенә шатлык өстәп торасың бит. Ял көнендә баскетбол ярышына барып кайтуымны әйтәм.

Үткән ялда йөгерештә катнаштым. Аннан алдагысында шашка-шахмат... Йөзү ярышына җибәргән өчен дә рәхмәтемнең чиге юк. Шәрә хатыннарны тагын кайда күрер идек.

Әле бүген Кипрга киткәнеңне белгәч тагын бер куандым. Ярый әле, минәйтәм, ял итәргә дә мине җибәрмәгән. Китәр идең башыңны иеп Кипрга. Кайтышыңа сыер юк — ачтан үлгән, хатын да юк — үчләшеп кыз янына китеп барган. Коточкыч! Күз алдыма шулар килә дә, рәхмәтләрнең ниндиен генә әйтсәм дә, әйтеп бетерә ал мам кебек. Әйтермен әле, пенсиягә чыккач, Алла боерса.





# Уртак хисләр

## УРТАК ХИСЛӘР

Башлык бүлмәсенә үгез муенлы, кыска кәкре аяклы, күлмәк якалары ат камыты шикелле ике якка ачылып китмәсен өчен аллы-гөлле чуар галстук буган бер адәм килеп керде. Ул "Якты төн" күмәк хуҗалыгы персиятеле Моталлап иде. Йөзеннән гөрләвек булып тир ага, ә аркасыннан агып төшкән тир трусигына кадәр юешләткән.

-Калхуз бетте, Хан  Солтанович, — диде персиятел, мыш-мыш сулап.—   Төнлә сыерларны алып чыгып бетергәннәр.Соңгы "Т-40" та күренми. Печән белән салам да юкка чыккан.

— Милициягә әйттеңме соң, пынимаешь? — диде башлык, һәрвакыттагыча бер җөмләсен вәкарь белән генә ике мәртәбә кабатлап.

— Әйттек-әйттек. Башта былтыр югалган сарыкларыгызны, дуңгызларыгызны табыйк әле, — диделәр.

— Атлар, чәчкечләр, ургычлар да табылмаган. Шуларның очына чыксак, бәлки эзли башларбыз, — диделәр.

—Бәлки ,диделәрме, пынимаешь?

-Нәкъ шулай диделәр, Хан Солтаныч.

—Инде яши башлыйбыз дип кенә торганда бит, Солтаныч. Еллык хезмәт хакын бирәбез дип торганда...

Бу сүзләр башлыкның ачуын кабартты:

-Син нәрсә монда..сырлап утырасың, тавык мие эчкән нәрсә! Син Бохар ишәгенә кем ышансын, ананңны сатыйм! Көпә-көндез шуның кадәр әйбер юкка чыга димени?

Кибән кебек кабарып утырган персиятел тылсымлы таяк белән суккан кебек урындыгына сеңеп, кечерәеп калды.

—Ур-ур-лау-у-у-ла-арын ни... ни... чек рас-с-с-ларга соң, Хан С-с...ол-таныч?..

—Амбар кенәгәләрегез бардыр бит? .

 — Юк шул, кичә контурыбыз янды бит, Солтаныч.

Башлыкның борын тишекләре персиятел сыярлык булып киерелде:

—Шуннан?

—Шуннан шул инде, — диде Моталлап. — Нишләргә дә ниткән юк.

—Җыелыш җыеп берәр нәрсә әмәлләп карагыз. Урладылар, янды дигәнгә ышанырлык заманмы? Кәгазь кирәк, пынимаешь. Кыштырдаган кәгазь кирәк.

—Акчасы исән-сау ла аның анысы, - диде Моталлап. — Акча минем машинада иде.

—Аңлатыбрак сөйлә, — диде башлык.

—Сыерлары да күрше калхузда. Сарыклары да. Сыер да, сарык та булмагач печән белән саламны череп әрәм булмасын дип үзем озаттым. "Т-40"ны гына аңлап бетермим. Каравылчы карт та белми...

—Эчәме?

—Кем?

—Синең чумеч белән чумергәненне беләм

—Салгалый.

—Акчаны син бирәсеңме?

—һы-ыһ!.. — адәм аңламаслык аваз чыгарып персиятел торып ук басты һәм таеп егыла язды, чөнки урындыгы астына әллә ботинка кары эреп, әллә башка җирдән агып, хәйран гына су җыелган иде.

— Син дә бирмәгәч, пынимаешь, мин дә бирмәгәч, каян табып эчә? Урлый, ызначит.



Шундый катлаулы мәсьәләнең җайлы гына чишелүенә килеп җиткән калхуз персие май кояшы кебек яктырып китте.

—Шул эчү аркасында инде, Солтаныч, эчү аркасында. Яши генә башлыйбыз дип торганда. Шул картка ышанып харап булдым. Кайту белән каравылдан алып ыргытам мин ул карт тәрене. Аксак крич! Чулак-чукрак инвалид кисәге! Кабахәт! Бөтен калхуз малын ничек эчеп бетермәк кирәк! Ни... Акчаны барыбер бирәбез, Солтанын, быел булмаса киләсе елга бирәбез.



Башлык шаркылдап көлеп җибәрде.

—Андый бәхет сиңа эләкмәс, - диде ул. — Бүгеннән сине "Караңгы көн"гә күчерәбез. Син әле яшь, энергияле белгеч. Давай, күрсәт үзеңне.

Икесе дә торып бастылар. "Яшибез, яшибез!" — дип типте йөрәкләр. Аларның икесенең дә уйлары уртак иде.



# Базар

## БАЗАР

Галине "Ашыгыч ярдәм" машинасы алып китте. Аны машинадан төшереп ятканда янына чибәр кыз килеп басты.

-Абый, хатыныгызга кыстыргычлар алыгыз. Канатлы кыстыргычлар, — диде ул кулындагы пакетларны җилпеп.

Ул арада бер егет кисәге пәйда булды.

-Япон презервативла-ры, — диде ул, елмаеп. — Соңгы партия. Алып калыгыз.

Санитарлар сырхауханә ишеген ачу өчен носилкада яткан Галине җиргә куйдылар. Шул арада аның янына биш-алты кеше җыелып өлгерде. Берсе Галинең чыраена сигарет төртте, икенчесе - теш щеткасы, өченчесе сагыз тәкъдим итте, дүртенчесе дерелдәгән хәлсез кулына догалыклар тоттырды.

— Алыгыз, ал, — дип шаулаштылар алар бөтенесе бергә. — Арзан вакытта алып калыгыз. Иң арзаны бездә генә.

Галинең тоныклана башлаган күзләре үзенә таба йөгерүче тагын бер көтү кешене шәйләп калды. Бәхетенә каршы, ишек ачылып, эчкә керделәр.

Озын коридорда сәүдә рәтләре тезелеп киткән иде. Ишек төбендә үк кәләпүшсез бер үзбәк черек өрек сатып утыра. Арырак сәүдәгәр әрмән шыкырдап каткан как .тәкъдим итә: Галинең күз алдыннан бананнар, трусиклар йөзем, җимешләре, лифчиклар, тагын әллә. нәрсәләр йөгереп үтте. Ниһаять, коридор башындагы лифтка барып җиттеләр. Бишенче катка менәргә

кирәк иде. Лифтка керделәр. Монда марҗа хатыны сыра белән кипкән балык, татар карчыгы симәнке сата булып чыкты.

- Кайшы кешәнә шалыйм? - диде карчык авызыннан аракы исе аңкытып.

Лифттан чыгып авыруларны кабул итү бүлмәсенә керделәр. Биредә интеллигент кыяфәтле адәмнәр Галигә Израильдәге иң арзанлы ял йортларына путевкалар төртергә маташтылар, Америкада дәвалану белән кызыктырдылар, бөтен чирдән дәвалый торган тылсымлы талисманнар күрсәттеләр.

Табиблар Галине чишендереп, әгъзаларын тотып-тотып карадылар, күкрәген тыңладылар. Аннан рентген бүлмәсенә алып киттеләр.

Бүлмәнең караңгы почмагында юан ботлы ярым шәрә ике кыз интим хезмәте күрсәтергә атлыгыптоталар иде. Ләкин Гали боларының күпме торганын ишетергә өлгермәде: ул, һушын, җуеп, рентген өстәленә ауды



# Эт



Кич иде. Эштән кайттым. Ишек төбендә бер эт утыра. Кызганып, өйгә керттем. Бер стакан сөт салып бирдем.

Бераздан ишектә кыңгырау чылтырады. Барып ачтым. Чайкалып бер сәрхуш тора. Күзенең агы белән карады да:

– Минем әнчек кайда? – ди.

– Миңа бер эт керде, – дим. – Белмим, синекеме, юкмы?

– Жирәнме? Кәкре аяклымы? Авызы менә мондый дәүме?

– Әйе.

– Шул инде, кабахәт. Ник керттең?

– Үзе керде. Кызганыч бит. Баскычта елап утыра.

– Эчерттең дәме?

– Бер стакан салып бирдем.

– Тфү, хайван! Инде йоклыймы?

– Йоклый.

– Синең яндамы?

– Соң... үзе килеп ятты.

– Үтерәм! – диде сәрхуш. – Үтерәм әнчекне! Бар әйт, чыксын монда.

– Ничек аңласын ул мин әйткәнне?

– Керә белгән бит, әнчек! Аңлашкансыз да.

– Эт беләнме?

– Кем белән булсын, шул ана көчек белән. Мин эчәргә эзләп чыгып киттем, ул шул арада синең янга шылган.

Әйдә, өчәү эчәбез. Бар, чыгар әнчекне. Югыйсә, күрсәтәм күрмәгәнегезне! Чыгар Аськаны диләр сиңа!

– Нинди Аськаны? – дим тагын, гаҗәпләнеп. – Син бит эт эзлисең.

– Ахмак. Эт – шул хатын бит инде... Ягъни хатын – минем эт...

Шул вакытта баскычта “пуф-пуф” килеп, алпан-тилпән атлап менүче хатын күренде.

– Күпме эзләргә була сине, собакы! – диде ул иренең изүеннән эләктереп. – Кайда сөйрәләсең син, алкаш, эт җан!

– Аська, Асенька, – дип мыгырданды сәрхуш. – Бәгърем, син өйдә юк идең бит... Мин сине эзләдем, алтыным, җанкисәгем...






# Тигез күтәрик!

Кызык иттем хатынны. 8 Март көнне йокысыннан уятмадым. Атна буе паласны какмыйсың дип үзәккә үтә иде. Рәхәтләнеп тәпәләдем! Бөтен үчемне алдым.

Кичтән табак-савыт юылмыйча калган иде. Бүген сеңелләре киләсе. Алар килешкә кашык-тәлинкәләрне юып куйыйм әле. Әйтеп карасын шуннан булышмый дип.Үтүк эшләми дип бер ай колак итен ашаган иде, аңа яңа чыбык ялгадым. Телсез кала инде моны күргәч.


Ут сүндергеч эшләми иде. Шөребен борып ныгытып куйдым. Шаккатсын!Суыткычны да суыта торган итсәм, валлаһи, кан басымы күтәреләчәк моның. Рәхмәт хөкүмәткә, елына бер тапкыр ирлекне күрсәтү хокукы биргән өчен. Рәхәт мәллә ул көн саен пычак үтми, ишек ябылмый, ут янмый, сәгать йөрми дигән сүзләрне ишетеп тору. Менә моннан соң әйтеп карасын. И тилмерәчәк, и азапланачак инде бәйләнергә сүз таба алмыйча.Ярты ел буе ишек тоткасы сынган килеш торган иде. Алыштырдым! Ачып чыкканда йөрәк өянәге алып егылмаса ярый инде.Идәнне дә юып чыгарсам, бөтенләй хатынсыз калмам микән? Шулай да сөртеп алдым, бәлки күрмәс. Тәмам коралсызландырдым җанкисәкне. Белсен моннан соң безнең кадерне. Сөенечемнән нишләргә белмичә, ай буе асылынып торган сервант ишеген ныгытып куйдым. Идәндә аунап яткан браны стенага беркеттем. Куана-куана аларның тузаннарын сөрттем, көзгене чистарттым. Хатынның көлкегә каласын күз алдыма китерә-китерә китап шкафын тәртипкә китердем.

Булгач-булгач бөтенләй авыз ачмаслык итәргә кирәк. Кибеткә чаптым. Хатынга чәчәкле-чуклы күлмәк алдым. Белсен иренең кемлеген! Бу сиңа 23 февральгә алып биргән базар ноские гына түгел инде,

җанашым. Боларны күргәч, артына утырмаса ярый инде шапылдап. Артыгын кыланып ташладым, ахры.

Ул арада хатын торып чыкты. Чыкты да, өй эчен күздән кичереп, ухылдап диванга егылды. Аның шар булып ачылган күзләре идәнгә, идәннән стетенадагы брага, брадан тоткага, тоткадан сервантка тәгәрәде. "Хәлим, әйт, зинһар, – диде ул дер-дер килеп. – Әти-әниләр исәндер бит?” Ул йөрәгенә тотынды. Мин валидол эзләргә керештем. Без шулай мәш килеп ятканда дуылдап баҗалар килеп керде. Алар да бездәге чисталыкны, тәртипне күреп шаккаттылар. Ә хатын тора авызын ачып, әйтергә сүзе юк чөнки. Менә шулай була ул. 8 Март сезнеке генә түгел, безнең дә бәйрәм. Шаярмагыз безнең белән! Аш пешкән, чәй кайнаган. Хатыннар, утырышыгыз табын янына. Әйдәгез, күтәрдек! Тигез күтәрәбез! Тормышны дим, бәгырь кисәкләрем, тормышны!





## КИТӘМ КИПРГА!

Алла боерса, быел җәй Кипрга ял итәргә барам әле. Үткән ел Анталиягә җыенган идем. Үч иткәндәй, җәй башында сыер бозаулады. Өченче ел, күпме әзерләнеп, Мисырга бара алмый калган идем. Колхоз ул елны хатын белән икебезгә өч гектар чөгендер бүлеп бирде. Җәй буе үстереп, көзен җыеп тапшыргач, һәркайсыгызга бирәр капчык шикәр бирербез диделәр. Шыкырдап торган ап-ак шикәрне ни җаның белән кара гарәпләргә алыштырасың? Бармадым, билгеле.

Быел, бисмиллаһи, барам булгач, барам Кипрга. Сыеры да, чөгендере дә чукынсын. Сәламәтлек кадерле. Сыер быел, Аллага шөкер, кысыр калды. Колхоз да чөгендер утыртмый. Үсми ул шикәр чөгендере безнең якларда.

Инде елын оныткавмын, колхоз персие Төркиядән башын тишеп кайткан елны бугай, Канар утрауларына җыенган идем. Сигезенчедә укыган Мансурның биш фәннән “ике”лесе чыгып, көзге сынауга калды, мөртәт! Беркөн авылга кайткан иде әле. Өч машина белән. Африкада эшли икән. Миңа да ике банан кертеп чыкты. “Маймыллар ашый торган чын бананнар бу, Фәрит абый, рәхәтләнеп сыйланыгыз”, – ди. Үзе көлә: “Картадан илләрне күрсәтә алмаган өчен “ике”леләрне тезә идең. Хәзер беләм инде. Бөтенесен йөреп чыктым”, – ди. Шуларны ишеткәч, күңелләр нечкәреп китте. Хезмәтеңнең җилгә очмавын күрү күңелле шул...

Ельцин Арча сабантуена килгән җәйдә Гарәп Әмирлекләренә бармакчы булган идем. Тагын ходайның “амин” дигән чагына туры килмәде. Башта колхоз сарыклары өчен яфрак җыйдык. Аннан чүплектә кычыткан чаптык. Мәктәп түбәсен яптык. Купкан идән такталарын кактык.

Соңгы кадакны сукканда

укуга чакырып, кыңгырау чылтырады...

Хәзер җайлы, кая барыйм икән дип баш ватып торасы юк. Телевизордан көн саен почмакларын күрсәтеп торалар. Җитмәсә, путевкалары да бик арзан икән. Кипрга бару өчен нибары 450 у.е кирәк ди. Ул уемуе дигәнен математикадан рубльгә әйләндереп караган идем... нокталарым өтергә әйләнеп күренә башлады. Минем отпускы акчасы гына бу оҗмах ишекләрен ачып керергә җитеп бетми икән. Ярар, бәҗайдан әҗәткә алып торып булсын ди. Процент белән. Әмма хатын тукылдый бит әле. Бакча коймаларын яңартасы бар ди. Мунча миче җимерелеп төшә башлады. Тавык-чебешләргә юньлерәк урын әмәлләштерергә кирәк. Аннан бәрәңге корты мыжгый башлый. Көтү чираты житә. Сыерга печән әзерләү, утын кисү, бәрәңге төбенә өю кебек пүчтәк эшләр янына мәктәпне, классларны ремонтлау кебек “сурьезный” эшләр килеп баса. Өстәвенә, Казанга барып энекәшнең җиде ел буе эшләнеп бетмәгән дачасын күтәреп бетерәсе бар. Хатынның апасы мунча төзергә көтеп ята. Тагын... Житте! Сыерны сатып отпускы акчасына кушарга да, тизрәк ычкынырга кирәк. Китәм булгач, китәм Кипрга!

Хәерчегә җил каршы дигәндәй, иң элек отпускы акчасының үз вакытында булмаячагы ачыкланды. Авыл Советы пенсиядәге укытучы Хәтимә апаның өен сипләп бирергә кушкан. Ашыгыч ди. Рәиснең июльдә Крутушкага путевкасы бар, шунда киткәнче эшләп бетерергә кирәк ди. Бу булды – бер. Икенчесе, иң мөһиме: анысын директор үз бүлмәсенә чакырып сер итеп кенә әйтте (сез дә сөйләп йөрмәгез!): мәктәп өчен би-ик кирәкле бер абзыйга дача саласы бар икән. Шунда бесплатный командировкага китәчәкбез ди. Директор әйтә: “Зинһар, егетләр, августка кадәр эшләп бетерик, Кырымга кызынырга китәсем бар”, –ди.

И-и-их! Җәй көне – укытучы, кыш көне агроном булыр идем дип өзгәләнгән абзыкаем, кайларда тилмереп йөрисең икән син? Кил безнең авылга, кил әйдә, кил! Бирәм мәктәбен черек идәннәре, су аккан түшәмнәре белән. Классын да бирәм, ватык тәрәзәләре, шкафлары, җимерек диварлары белән. Надан укучыларын да бирәм, җәл түгел. Хатынны да... Чү, тукта! Анысы ук ярамас. Юлда ни килеп чыкмас. Китәм булгач, китәм инде. Җәяүләп булса да китәм Кипрга!




# Уйлар

Өйләнү – лотерея түгел. Лотереяда әле оту ихтималы бар.

Хатын-кызның мәңгелек соравы: ябыгу өчен нәрсә ашарга?

## ЯРТЫЛЫ ХИСАП

Яшәүмени бу! Ай буе бер көн эчмичә эшләп, 2 мең ярым акча бирделәр. Тфү! Бу бит барлы-юклы 50 ярты дигән сүз! Без өйдә 4 кеше. Нәрсә, миңа бары 12 ярты тияме? Ике көнгә 1 ярты чыга. Уф! Газга түлисе бар. 5 яртылык аңа китә. Утка тагын 1 әү. Телефонына 2 ярты. Мелт-мелт килеп мөлдерәп торган 8 урыс малаен җиңел генә чыгарып бир әле. Үз кулларың белән! Ай буе яшәргә ни кала? Сыерны страховать итәсе бар, 600 гә. Менә тагын китте 12 шешә дигән сүз. Хет асылын! Өй страховкасы 20 яртылык. Безнең Татарстан аракы эчү буенча Русиядә икенче урында тора дип мактанган булалар тагын. Ялганламагыз! Сөйләмәгез юкны! Ишетсәләр, тавыклар егылып көләр. Эчәрсең монда! Әле малайга мәктәптә ашаганы өчен 3 яртылык акча бирмичә булмый. Бакчада йөргән кечкенә кызга 2 дә житә. Үземә тәмәкегә ике шешәне өстәсәң, күпме кала? Шымытыр да калмый. Каравыл! Пычаксыз суялар, кычкыртып туныйлар. Әле сыерга фураж алмаган, салам бетеп килә. Шулай итеп эчәргә бер ярты да калмыймыни инде? Ай буе эшләп, рәхәтләнеп бер ярты да салмагач тормыш буламы инде бу?! Һәм сез шушыны яшәү дип ышандырмакчы буласызмы? Юк, хәзер чыгып китәм дә әҗәткә бер ярты алам!





## КҮКӘЙ ХИКМӘТЛӘРЕ

Авыл кибетләрендә дәүләткә күкәй җыйган чор. Ул вакытта ипие дә, бәби чүлмәге дә бер кибеттә. Шакир абый Казанга туганнарының туена барырга җыенып йөри. Шәһәрчәрәк күренергә тырышып, галстук тагарга уйлый бу. Кибеткә килә, карый – түрдә, сырган бишмәт өстендә, бер чуар галстук эленеп тора.

– Сеңлем, миңа әнә теге гластукны бир әле.

– Галстук күкәйгә генә, Шакир абый, – ди төелә-төелә ипи белән сөт ашап утырган кибетче кыз.

Шакир абзый, уңайсызланып:

– Миңа муенга тагарга кирәк иде шул, – ди дә кибеттән чыгып китә.

Шулай итеп, аңа туйга галстуксыз гына барырга туры килә.

* * *

Элек авыл кибетләрендә күкәйгә сатыла торган әйберләрнең исемлеге һәм кемнең күпме күкәй тапшырганын күрсәткән дәфтәр эленеп тора иде. Шунда ук – “Гражданнар! Дәүләткә күкәй тапшырыгыз!” дигән лозунг-өндәмә. Безнең малай чак. Кибеткә прәннек кайткан дигән хәбәрне ишеттек тә, тегеннән-моннан яшереп куйган шешәләрне алып, кибеткә чаптык.

Кибетче бер безгә, бер алдындагы дәфтәргә карап-карап торды да:

– Башта әтиләрегез килеп, күкәйләрен тапшырсыннар, аннан прәннек ашарсыз, – дип, безне кире борып җибәрде.

* * *

Җыелышта сельпо рәисе кибетче белән клуб мөдирен сүгә (ул чакта клуб мөдирләрен өйдән-өйгә йөреп күкәй җыярга мәҗбүр итәләр иде):

– Берегез коммунист, икенчегез комсомол. Күкәебез юк дип утырырга ничек оялмыйсыз?!

Кып-кызыл булган клуб мөдире Зөһрә:

– Мин әйтмәдем. Әнә, Гали абый әйтте, – диюгә бөтен авыл клубы шаркылдап көлеп җибәрә.

* * *

Мәктәпкә Ветеринария институтыннан чыгарылыш сыйныф укучылары белән очрашып сөйләшергә, үзләренә укырга килергә чакырып ике укытучы килеп төшә. Директор ашханәдә эшләүче Асия апага: “Тиз генә кил! Күкәй булса да пешереп бир”, – дигән язу җибәрә.

Укытучылар бүлмәсендә утырабыз. Берзаман, сулуы кабып, Асия апа йөгереп килеп керде. Кулында зур гына пычак.

– Күкәйләрегезне нишләтим? – диде ул, шар ярып.

Килгән кешеләр бер-берсенә карашып алдылар да безгә табарак елышып утырдылар.

Асия апа дәвам итте:


– Табада куырып биримме, бөтен килеш кенә пеширимме?

* * *

Шәһәрдән килгән чит тел укытучысы Эльза районга барырга җыена. Колхоз шоферы Гариф абзый яшь кызга машина әрҗәсенә менеп утырырга куша. Ә анда кибетче Нургали абыйның күкәй тутырылган тартмалары.

– Син анда Нургали абыеңның күкәйләрен тоткалап бар инде, җәме, – ди шофер, укытучы кызга.

– Юк, юк, алайса мин утырмыйм, – дип, Эльза зур юлга җәяүләп кенә чыгып китә.




# КЫЗЫЛ КАР

Әстәгъфирулла! Иртән йокыдан торып, тәрәзәгә күз салган идем – егылыплар китә яздым: бөтен дөньяны тутырып кып-кызыл кар яуган! Кечкенә чагымда: “Әти, сәпид алып бир әле”, – дигәч, аның: “Кызыл кар яугач алырбыз, улым”, – дигәне хәтердә. Менә бит, яуган кызыл кар!

Шапыр-шопыр салкын чәй чөмердем дә чаптым мәктәпкә. Алтынчы дәрескә план төзелеп бетмәгән, тикшерсәләр, бетте баш! Мәктәптә серле тынлык. Әүмәкләшеп сугышучы, аяк чалып егучы, баскыч астында тәмәке пыскытучы малайлар кая киткән? Ходаем, бүген ял көнеме әллә? Юк икән, әллә каян гына балкып, завуч Илсөяр Якуповна килеп чыкты: “Хәерле иртә, Рәшит Сабирович, – диде. – Хәлләрегез ничек? Бүген директор ачык дәрес үткәрә. Рәхим итегез”.

Идәннәр чайкалып, түшәм өстемә төшкәндәй булды. Ни үле, ни тере хәлдә кереп киттем дәрескә. Егерме укучы, төз наратлар кебек туры басып, миңа текәлгән. Ник берсе чапылдатып сагыз чәйнәсен, ник берсе урындыкка инә куйсын. Чүпрәкләр, акбурлар очмый, сызгырган, мәче чинаган тавышлар да ишетелми. Өйрәтелгән этләр кебек күзгә карап тик торалар. Нишләргә? Башта акырырга, аннан берәрсен җилтерәтергә, соңгы чутта указканы сугып сындырырга тиеш бит мин. Нинди хәл соң бу? Бәрәкалла, ә монысы нәрсә тагын? Түрдә мин биш ел буе теләнеп сораган телевизор кукраеп утыра. Янәшәсендә магнитофон. Стена кырыенда компьютерлар тезелеп киткән.

– Утырыгыз! – дидем, көч-хәл белән күтәрелде. Үтерәләр! Пычаксыз суялар бит болар бүген!

Кемгә “2”ле куярга икән дип тешемне шыгырдатып журналны ачтым. Беренче сорауны ишетүгә, шәм кебек егерме кул

– К... к... каюмов, сөйлә, – дигән булдым.

Кулына гомерендә китап тотып карамаган Каюмов университет профессоры шикелле сөйләп тә китте.

“Бетүләрем шушы икән!” – дип уйларга да өлгермәдем, ишек шакыдылар. Сәркатип кыз Ләйлә икән. “Рәшит абый, акча кайтты, зинһар, кереп алыгыз”, – ди. Барсам, минем кул куеп ала торган 3 мең урынында 30 мең тора. “Ялгыштыр бу”, – дип әйтергә өлгермәдем, Ләйлә кулыма тагын 10 мең тоттырды. Монысы премия икән. Шуннан соңгысын бик үк хәтерләмим...

Ямьшәйгән бүрек колакчынын тешләп идәндә яткан җирдән көч-хәл белән тордым. Тәрәзәгә күз салдым. Кызыл карның эзе дә юк. Телефон чылтырады. Завуч икән. “Син, Сабиров, күпме ятарга уйлыйсың? – диде ул гөбедән чыккан тавыш белән. – Дәресләреңне кем укытыр? Ишетәсеңме, иртәгә мәктәптә бул! Премияңне кистерәм!”

Рәхәт булып китте. Сулышлар җиңеләйде. Аллага шөкер, тереләм икән болай булгач. Кызыл кар гына ява күрмәсен...






# САБАК

САБАК

Алгы партада утырган малай сумкасыннан болан мөгезе кадәр рогатка чыгарды.

– Ашыкма, – мәйтәм тегеңә. – Наданлыгыңны күрсәтмә. Синең шикелле егеткә кәкре агач кисәге тотып утыру бөтенләй килешми. Синең кулда җунлерәк нәрсә булырга тиеш: йә пистолет, йә автомат...

Ул аз гына уйланып торды да рогаткасын сындырып ташлады.

– Таныш булыйк: мин сезне тарих белән географиядән укытачакмын, – дим. – Сызым белән рәсемнән дә кергәләп чыгармын.

Шулчак пычак ялтырап китте.

– Әһә! – дидем мин зур куаныч белән – Менә бу корал! Әмма минекенә җитми. Дустым миңа Колымадан алып кайткан пычакны күрсәгез, исегез китәр. Иртәгә алып килермен.

Пычак бүтән күренмәде. Әмма арткы партадан миңа пугач төбәделәр.

– Бик яхшы, – дидем, шатлыклы кыяфәт чыгарып. – Дәресне башлаганчы, әйдәгез, башта ату ярышы үткәреп алыйк. – Шап итеп өстәл уртасына глобусны китереп утырттым. – Кем дә кем Памир тавына тидерә, шуңа географиядән “бишле”. Тик бер шарт белән: кыек атучының маңгаена мин турылап үзем чәпәчәкмен.

Класс шым булды. Берничәсенең нервысы чыдамады: парта астына төшеп. тәмәке кабыздылар.

– Кеше көлдермәгез инде, – мәйтәм. –

Кем инде шундый чүп тарта?

Кесәмнән сигаралар чыгарам. Тәмәке тартучы малайга дәһшәтле сорау бирдем:

–Йә, сөйләп җибәр әле, бу сигараларның

кайда эшләнүе турында. Белмәсән, тәмәкеңне артыңа төртәм. Алга таба тәртип шундый булачак.

Тәмәке төтене сүрелде.

– Бүтән һаваны бозмагыз, – мәйтәм. – Башка вакытта мин кергәндә классыгызны җилләтеп куярга онытмагыз. Һәм тагын бер кисәтеп куям: дәрестә кәрт сугарга уйласагыз, минем карталар белән генә уйныйсыз. Минуты –Ун сум. Шылдымы?

Кыңгырау чылтырады, мин горур кыяфәттә класстан чыгып киттем. Чираттагы дәрес – 8 нчеләрдә. Аларга да шәпләп бирәсе булыр сабакны.



# «САБИРНЫКЫЛАРНЫ КӨТӘМ»

Житмешенче еллар. Көз. Бәрәңге алган вакыт. Туктаусыз яңгыр сибәли. Көн аз гына ачылуга, халык кырылып бәрәңге бакчасына ябыша.

Шимбә көнне хатыннарның (әле ул вакытта яшь, чибәр кызның) күршесе Сабир абзыйларга Казаннан көтүләре белән туганнары, балалары кайтып төшә. Ә яңгыр сибәли дә сибәли. Бу кадәр кешенең өйдә өелеп ятуы да эчне пошыра. Өй бакчасы торып торсын, басу бакчасын алырга кирәк, дип уйлый Сабир абзый. Кыр да җилләгәндер, алуы җиңелрәк булыр.

Төштән соң яңгыр бераз туктагандай итә, кояш та чыккалап ала. Нишләргә белми бәргәләнеп йөргән Сабир абзый фәрманын җиткерә: “Басу бакчасына барасыз!” Олысы-кечесе көрәкләр, сәнәкләр күтәреп, басу бакчасына юнәлә. Сабир абзый, сәламәт булмау сәбәпле, өй саклап кала.

Ул чорда басу бакчалары авылдан читтә, бөтен кешенеке бер җирдә. Араларында беленер-беленмәс кечкенә генә межа. Казан кунаклары, җир җимертеп эшләп, кичкә бәрәңгене алып бетерәләр. Кырда капчыклар утырып кала, үзләре азрак ял итәргә, чәй эчәргә дип өйгә кайтып китәләр. Бераздан ат табып, бәрәңгене төяргә басуга киләләр. Ә анда бөеренә таянган Камал абзый басып тора:

– Сез нишләп минем бәрәңгене алдыгыз? Кем кушты? – дип җикеренә ул. – Мин җир суыклары кергәч кенә алырмын дип тора идем. Хәзер кая куям мин бу бәрәңгене? Идән асты каралмаган, баз чистартылмаган...

Сабир абзыйныкылар коелып төшә. Ә Камал абзый тузыныпмы тузына. Бераздан килешәләр тагын. Ат арбасына төяп, Камал абыйны җайлап-юмалап, бәрәңгесен өенә кайтарып бирәләр.

Шуннан соңгы елларда: “Бәрәңге алмыйсыңмы әллә?” – дип сораучы кешеләргә Камал абзый, мыек астыннан гына елмаеп: “Сабирныкыларны көтәм”, – дип җавап бирә торган була.




# “ГӘЛИ ТҮЛӘСЕН!”

Авыл кибетендә аракыны кырлы стаканга бүлеп бирә торган еллар. Ирләр эштән туры өйләренә кайтмыйча, башта шунда сугыла. Гәли абзый да. Беркөнне стаканга йөз грамм салдырып торган чакта, кибеткә хатыны Шәмсия килеп керә: “И-и, Гәли, җаным, син дә монда икәнсең, әйбәт булды әле бу”, – дип сайрый башлый ул. Һәм сумка тутырып әйберләр алырга керешә. Прәннек тә ала, кәнфит тә, шикәр-токмач, банкалы кайнатма, консервы – күзе нәрсә күрә, берсе дә калмый. Алып бетергәч, аллы-артлы күтәренеп кибеттән чыга башлый.

– Ә акча? – ди кибетче, аптырап.

– Син нәрсә? – ди Шәмсия апа. – Син минем кем хатыны икәнемне белмисеңме әллә? – Һәм күзләре акайган иренә төртеп күрсәтә. – Әнә, көн саен эчәргә тапкан Гәли түләсен!

Шул хәлдән соң абзыебыз кибеткә бөтенләй кермәс була.

# ШАКИР МАҖАРАЛАРЫ




Житмешенче еллар. Шакир абыйның элемтә бүлегендә бригадир булып йөргән вакыты. Ул көнне аның әбәд алып килү чираты була. Иртән эшне оештырып җибәргәч, авылга кайтып китә бу. Кайта да, ашамлыклар алып менәргә дип, базга юнәлә. Аска төшеп, аяк җиргә тия дигәндә генә, дөңгердәтеп катык чиләгенә китереп баса. Катыкка чумган Шакир абый сукранып баздан менә дә, урамдагы су колонкасына чыгып, кәстүм-чалбарын юып чистарта. Аннан ашыга-ашыга печәнлеккә менеп китә. Тавык оясыннан йомыркаларны алып төшеп, пешерергә куя. Бакчадан суган, кыяр җыеп ала. Барысын бергә төйнәп, кырга китә. Кызулык белән таудан төшеп барганда велосипед көпчәге кыйшаеп торган күпер тактасына эләгә һәм Шакир абыебыз, бака кебек җәелеп, юл тузанына барып төшә. Катыктан юылып әле кибәргә өлгермәгән өс киеме баштанаяк тузанга бата. Кәстүмен салып елга кырыена килә дә, ачудан суда болгый-болгый, юа башлый. Чалбарын да сала. Аны фермадан кайтып килүче хатыннар күреп ала. “Абау, Шакир җүләрләнгән!” – диләр алар исләре китеп.

Шул арада Шакир абый юеш киемнәрен киеп ала да, велосипедына утырып басуга элдертә. Ләкин ерак китә алмый, гөнаһ шомлыгына каршы, көпчәк җибәргән булып чыга. Сәпидән җитәкләп, тирләп-пешеп эш

көткән егетләр чирәмгә тезелешеп утыралар. Шакир абый шунда төенчегенең юклыгын күреп ала. Бөтен ризык елга буенда калган! Нишлисең, кире барып алып килә. Тагын

тезелешеп утыралар егетләр. Берсенең йомырканы алып, маңгаена бәрүе була, ялтырап чеби аягы килеп чыга. Икенчесе әрчи башлый – чеби башы килеп чыга.

Өченчесе, дүртенчесе дә бозык. Шакир абый ачуыннан йомыркаларны тибеп очыра. Инде нишләргә? Ач егетләрнең ачуы яман. Шуннан, кылт итеп, иртәнге якта бригадасына аванс алганлыгы исенә төшә. Кулы белән түш кесәсен каплый, әһә, акчалар шунда. Ала, тик акчаларның барысы да лыч. Егетләр мөлдерәшеп карап тора моңа. Берсе ыңгырашып кына: “Җәеп сал чирәмгә”, – ди. Тезеп чыга Шакир абый берлекләрне, бишлекләрне яшел чирәм өстенә. Егетләр иренеп кенә тагын көрәкләренә тотыналар. Ул арада, көтмәгәндә, өермәле җил чыгып, бөтен нәрсәне туздыра башлый. Акчалар берәм-берәм һавага күтәрелә. “Тотыгыз, тот!” – дип акырышырга тотына егетләр. Һәм көрәкләр күтәреп, кепкаларын, өс киемнәрен салып, басу буйлап акча куарга тотыналар. Шактый вакыт мүкәли-мүкәли акча җыялар. Соңгы берлекне тоткач, Шакир абый шапылдап җиргә утыра. “Булды, егетләр! Бүген бүтән эшләмибез”, – ди.

Акчаны бүлешәләр. Шакир абый – алдан, артыннан – бригадасы, булып үткән хәлләрдән шаркылдап көлә-көлә, якындагы авыл кибетенә тәпилиләр.



# АТКАЗАНУ

Нихәл, Халисә! Шатлыктан чылтыратуым сиңа – малай эшкә керде бит! Мәктәпкә. Белеме дип... Бар, нишләп булмасын. Башлы бит ул. Армиядән кайтышлый Мәскәү вокзалында диплом сатып алган. Акчасы укытучыныкына гына җиткән. Прокурорныкы бик кыйммәт ди. “Бик шәп булган, улым, авылда хәзер иң акчалы урын мәктәп”, – дидем. Теләсә кемне алмыйлар бит әле анда. Әнә, Әхминең университет бетергән малае кызыл дипломын селкеп йөрде-йөрде дә, Казанга китеп, “Бәхетле”гә каравылчы булып урнашты. Ә директор безне сайлады, чөнки минем малай атасына охшаган, кулына балта-пычкы тота белә.

Мәктәптә хәзер укучы институтка керсен дип бик азапланмыйлар икән, чөнки вузларда хәзер балалар түгел, ә бозаулар укый. Минем энекәш абзарына өч бозау алып кайтып куйды инде. Улы тугызынчыда гына әле. Тагын дүрт бозаулык акча юнәтә алсам, малайны юристлыкка кертәм ди.

Минеке физкультура укыта. Хезмәт тә биргәннәр. Кибетче Фәүзия кызы бәби табарга китәсе ди. Шуның география дәресләрен дә өстәсәләр, 36 сәгать була. Бу араларда укытып мәшәкатьләнгәне юк әле, директор малаена шәһәрдә коттедж салалар. Директоры бик мактый үзен, әле ярый Хәбриев бар дип кенә тора ди. Минем малай да әрсез инде. Кая кушсалар, шунда чаба. Беркөнне чаңгы ярышына барса, икенче көнне көрәшкә чыгып китә. Аннан директорны балыкка алып барып кайта. Шимбәдә куян атарга китәләр.

Ә менә завучлары бер аждаһа. Шулкадәр эшләгән малайга планың кая дип бәйләнә икән. Язу-сызу белән утырганчы, директорның икенче малаена да өй сала башласак, эшләр хутка китәр иде дип йөри балакаем. Салдырыр, мин әйтәм, булдыклы кеше ул. Влач та, акча да үз кулында. Әле өстеннән жалу язганнар: дәресләрен укытмый, акча урлый дип. Укытса, урламаса юләр булыр иде, шуны аңламыйлар ахмак башлар. Халык бик әшәке, көнче бит бездә. Койрыгын кысып ятасы гына бит инде югыйсә. Районнан килеп төшкәннәр дә, пыр туздырып киткәннәр боларны. Директорга бәйләнгәннәр дип уйлыйсыңмы? Көтеп тор! Аның инде күптән кирәкле биреләсе бирелеп куелган.

Безнең малай, ичмасам, эшләп тә күрсәтә. Балаларга тәмәке тарту өчен аерым бүлмә




ясап куйды, хезмәт белән физкультураны бергә кушып укыта башлады. Мондый яңалыкны өйрәнми булмас дип, район газетасыннан килеп киткәннәр. Директор да берәр грамота бирми булмас дип әйтә ди.

Иң важныен әйтми торам икән. Тиздән мәктәпләрендә семинар үтә. Минем малайның укытуын өйрәнергә районның бөтен хезмәт укытучылары җыела. Ачык дәрескә. Укучылар эшләгән дип күрсәтер өчен таба астына куя торган такталар, балта-чүкеч саплары, тукмаклар, тагын әллә нәрсәләр эшләп бетерде инде. Тегеләр киткәч, барысын җыеп, өйгә алып кайтасы. Монысы әйбәт кенә үтеп китсә, атказанган исеме бирергә мөмкинлекләр дип куанып йөри мескенем. Бирерләр, Алла боерса, минем малайга да бирмәгәч, тагын кемгә бирсеннәр!

# КӨННӘРДӘН-БЕРКӨННЕ

**(Уенын-чынын кушып)**

Көннәрдән бер көнне телевизор экранында чырае агарынган финанс министры пәйда булды:

– Кризис бетте. Бүтән булмаячак. Бәяләр күтәрелмәячәк. Инфляция юк. Курыкмагыз! – диде ул.

Иртәгесен халык сүгенә-сүгенә тоз, шырпы җыярга кибетләргә йөгерде.

Икенче көнне телевизор экранына чырае кысага сыймаган сәүдә министры килеп чыкты:

– Ипи һәм товар бездә буа буарлык. Ачлык булмаячак. Ышанмасагыз, менә сезгә саннар...

“Ах!” – диде халык һәм кибетләргә он, ярма җыярга йөгерде.

Өченче көнне атка атланган авыл хуҗалыгы министры күренде һәм сөенче алды:

– Быел моңарчы күрелмәгән уңыш җыелды. Амбарлар ашлыктан ташып тора. Куяр урын юк. Артыгын Америкага сатабыз.

– Бетте баш! – диде халык һәм, ипи киптереп, сохари әзерләргә кереште.

Ул арада төзелеш министрын да күрсәттеләр.

– Фатир бәяләре төшә, – диде ул. – Студентлар коттеджларда яши башлаячак. Өй салырга бушлай җир бирәбез. Бомжларның һәрберсе фатирлы булачак!

– Бар икән күрәселәр! – дип ыңгырашты халык һәм утын, күмер, буржуйкалар хәстәрләү эшенә кереште.

Атна ахырында корсагы экраннан бүселеп

чыккан саклану министрын күрсәттеләр.

– Армиядә хәлләр күзгә күренеп яхшыра.

Солдатлар череп баеды, өйләренә миллионер булып кайтып китәчәкләр. Безнең танклар –дөньяда бердәнбер. Самолетлар – супер. Без җиңәбез. Ура!

– Әнекәем! – дип кычкырды халык һәм землянкалар казырга кереште.

Шушы хәлләрдән соң экраннарда башын кыңгыр салган иң зур түрә пәйда булды:


– Барысы да контрольдә. Уңышлар искиткеч, – диде ул. – Пенсияләрне тагын

арттырдык. Озакламый ут, газ өчен түләүләр бетәчәк, фатир – бушлай, транспорт бушлай булачак. Белем бирү, сәламәтлек саклау системасы турында әйтеп тә тормыйм. Ил чәчәк ата. Полициябез шәп. Барысы да контрольдә.

– Ләхәүлә вәлә куәтә! – диде халык һәм, гөсел коенып, чиста киемнәрен кия башлады.



# ЯХШЫ УКЫТУЧЫГА ӘВЕРЕЛҮ СЕРЛӘРЕ




**1. Класстан беркайчан да буш кул белән чыкмагыз**

Кәгазь тотып йөрүче укытучылар һәрвакыт эшем кешесе булып күренәләр. Кулында кәгазь булмаган укытучыны йә тәмәке тартырга, йә ашарга бара дип уйлыйлар. Ялгышып, дәрес буе укып утырган газетагызны күтәреп чыга күрмәгез, балалар сезне бәдрәфкә бара дип карап калачаклар. Эштән киткәндә сумкагыздагы әйберләрегез өстенә күренеп торырлык итеп кәгазьләр тутырыгыз. Иң мөһиме: сезнең күтәренеп-төялеп чыгып китүегезне күреп калсыннар һәм өйдә дә күп эшли икән дип уйласыннар.

**2. Компьютер артында еш утырыгыз**

Сез анда сайтыгызны яңартырга, почтагызны актарырга, чатта утырырга, һич югы, пасьянс уйнарга мөмкин. Завуч йә директор күренсә, шәп педагогик белешмәләр бар икән дип, аларга да керергә киңәш итегез.




**3. Өстәлегездә тәртип булмасын**

Буш өстәл – эшлексезлек билгесе.Чиста өстәл директорга гына килешә. Өстәлегезгә дәфтәрләр, китаплар, төрле методик китаплар һәм планнарыгызның барысын да таратып ташлагыз. Читтән караганда укучыларның үткән елгы иске дәфтәрләре дә быелгы эш дәфтәрләре булып күренә. Дәфтәрләрне эреле-ваклы кучләргә өегез. Завучка бирәсе отчетларыгызны, дәрес планнарын (әгәр булса) алдан ук үзегезгә билгелерәк урынга тыгып куегыз һәм тиз генә шулар арасыннан алып бирегез.

**4.Әсәрләнеп, хафаланып йөрегез**

Тәнәфесләрдә кызу-кызу атлап, каядыр ашыккан кебек барыгыз. Телефоннан сөйләшкәләп алыгыз. Берәр укучыга җикеренеп кую, кисәтү ясау бик үтемле чара, ул сезне мәктәптәге тәртип турында кайгыртучы кеше итеп күрсәтер. Чабып барган малайны җилтерәтеп, колагыннан сөйрәп директорга алып керсәгез, эффект тагын да көчлерәк булачак.

**5.Өегезгә чабарга ашыкмагыз**


Япониядә генә ул эштә тоткарланган кешене яратмыйлар. Бездә, киресенчә, күпме соңрак китсәң – шулкадәр яхшы эшләүче саналасың. Директордан алда өегезгә чабарга ашыкмагыз. Билгеле, ул киткәнне көтеп тик

карагыз, Интернетта казыныгыз. Инде кайтып китәргә уйлагансыз икән, директор ишеге төбеннән катырак басып үтегез, ишеге

ачык булса, сау булыгыз, иртәгә кадәр дигән матур сүзләр әйтеп узыгыз. Урамга чыккач эт итеп сүгәрсез. Кичке якта, ял көннәрендә (мунча кереп яткан вакыты булса бигрәк тә әйбәт) директорыгызга чылтыраткалап алырга онытмагыз, эш буенча берәр нәрсә сорагыз. Шуның белән сез үзегезне ял турында түгел, ә мәктәп турында кайгыртучы чын хезмәткәр итеп күрсәтәчәксез.

## 6. Сүз байлыгыгызны арттырыгыз

Компьютер терминнарын кыстырып сөйләшү кешегә көчле тәэсир итә. Әйтергә авыр, мәгънәсе аңлашылмаган 5-6 сүзне директор белән сөйләшкәндә һәрвакыт сөйләмегезгә кертеп җибәрегез. Инновация, аффектация, экзальтация кебек сүзләр арасына чистеросальпингэктомия кебекләр дә бик кулай. Сезгә директорның аңлавы кирәкми, иң мөһиме, ул сезне аңлы, белемле укытучы дип санасын һәм башкаларга үрнәк итеп куйсын.




## 7. Ике пиджак булдырыгыз

Бер пиджагыгыз һәрвакыт урындыкта эленеп торсын. Сез эштә булмаган чакта да бу бер генә минутка чыккан икән дип уйласыннар. Ә сез икенче пиджагыгызны киеп кибетләргә чыгып йөрегез, спортзалда туп тибегез, бассейнда коенып чыгыгыз, китапханәдә яңа газета-журналлар укыгыз. Һич югы, күрше бүлмәдәге яңа гына эшкә килгән чибәр кыз белән ләчтит сатыгыз.

## 8. Укучы көндәлеге – укытучының төп коралы

Билге кую мөһим түгел. Мөмкин кадәр күбрәк кисәтүләр, янау сүзләре языгыз, укучыларыгызның кимчелекләрен күрсәтегез, зарланыгыз. Ата-аналар өчен сез мәктәптәге иң шәп укытучыга әйләнерсез.

## 9. Җыелыш – үзеңне күрсәтү урыны

Җыелышта йоклап китмәс өчен телефоныгыздагы уеннар белән мавыгыгыз, дәфтәр тикшерегез, берәр детектив укыгыз, смслар языгыз. Төп момент – җыелышның соңгы минуты. Җыелыш башланганчы ук берәр сорау әзерләп куегыз. Сорау гомуми

булсын, купшы булсын. Берәү дә җыелышта сөйләгәннәрне хәтерләмәячәк, ләкин барысы да икенче җыелышка кадәр сезне һәм сезнең соравыгызны онытмас.



# АВЫЛ ЭРОТИКАСЫ

Хатыны урын җәйде.Ир барып тиз генә утны сүндерде.Караваt шыгырдап куйды.

-Булдымы?-дип сорады хатын.

-Юк әле,-диде ир,авыр сулап.

-Булдыксыз,-диде хатын.-Ирлегеңне әйтер идем...

Сүз бер капчык комбикорма турында бара иде.Ул инде күптән бозау тагарагы астына яшереп куелган.Сәлим шуны алып кайтырга җай таба алмыйча йөри.

-Җебегән,-дип дәвам итте хатын.-Бүген тагын ике чеби үлде.Кеше ирләре азыкны машина белән алып кайтып аударалар,син төнлә күтәреп кайтырга куркасың.

Сәлим бүген хатыны Сылубикә назлырак булыр дип көткән иде.Чөнки әбәд вакытында кыш айлары өчен мең тәңкә кайтарып бирде бит! Комбикорманы да алып кайтса менә...Сәлим хатынына елышты.Әчкелтем ферма исе,сенаж “хушбуе”аның башын әйләндерде.

Хатын дәвам итте:

-Бозауның эче китә.Көне буе тана мөгрәде.Үгезгә алып барырга уйламыйсың да...

Сәлимнең кулы хатынының җилкә чокыры тирәсенә шуышты.Кытыршы каты кулны Сылубикә җәлт кенә мендәр өстенә алып куйды.

-Атна буе каз оясын рәтли алмасаң да,хатынга үрелә беләсең тагы,-диде ул.-Бер биби ярыкка кысылып чак үлмәгән бүген.Болай да өч бәбкә.Кешедән оят.Казың да булдыксыз,үзең дә...

Бераз сүзсез яттылар.Ара-тирә караваt шыгырдап куйды.Сәлим үткән атнаны баҗаларында видиктан бер кино караган иде.Шуны исенә төшереп ятты.Вәт тормыш,вәт яшәү ичмасам.Андагы хатыннарның әрсезлеген,ах-вах килеп ыңгырашуларын күреп Сәлимнең исе китте.Күз алдыннан китмиләр генә бит шул кинодагы шәрә нәмәрсәләр.! Менә тагын шуларны уйлап,Сәлим хатынының йомшак беләген тотты.Ә ул шуны гына көткәндәй тезеп китте:

-Кыз мәктәпне бетерә.Чыгарылышка күлмәк кирәк ди.Малай сабантуйга аяк киеме сорый.Газга-утка түләмәгән.Электрны өзәбез дип киттеләр.Уф!...-Һәм ачу белән ирнең кулын алып ташлады.

Сәлимнең күз алдындагы дәртле шәрә хатыннар шундук гаип булдылар.Ул,тешләрен кысып,караваt кырыена шуышты.Эченнән генә бөтен шартын китереп өч-дүрт ай буе акча бирмәгән ферма мөдирен эт итеп сүгеп ташлады,юньләп баса белмәгән ата казны каргады,чебиләрнең җәһәннәмгә олагуын теләде.Аннан ачу белән урыныннан сикереп торды,Киенде.Ишекне шапылдатып ябып чыгып китте.

...Ул кайтканда Сылубикә мыш-мыш килеп таралып йоклап ята иде.Сәлим тиз генә чишенде дә юрган астына чумды.Салкыннан туңган куллар хатынының куенына чумды,аяклар җылы ботларга чуалды...

-Булдымы?-диде йокылы-уяулы Сылубикә.

-Булды,җаным,булды.

Караваt шыгырдап куйды.Рәхәт иде Сәлимгә!Әле генә алып кайтып куйган комбикорма аның күз алдыннан китмәде.Чукынып китсен шәрә хатыннар.Лапастагы бер капчык комбикорма әллә нинди дәртле хатыннардан да кадерлерәк иде аңа бу минутта.

# БӘЙРӘМ КОНЦЕРТЫ

Кадерле әти-әниләр һәм яраткан укытучыларыбыз! 7а сыйныфының сезнең хөрмәткә әзерләнгән бәйрәм концертың башлыйбыз. Концертны Марс Шакиров алып бара. Дөресрәге, тиеш иде. Ул шушы бәйрәм хөрмәтенә үткәрелгән ярышта егылып аягын сындырды. Шуңа концертны мин алып барам. Мин сезне тагын бер тапкыр бәйрәм белән тәбрик итәм. Шул уңайдан программа буенча "Әнкәмнеңдогалары" дигән жыр булырга тиеш. Ләкин аны жырлаучы Гүзәл Йосыпова кичә "Чибәрләр" конкурсына китеп барды. Күңелегез төшмәсен, кадерле әниләр, этиләр һәм яраткан укытучыларыбыз. Хәзер биеп алабыз. Бакый Садыйков , "Көтүчеләр" биюе. Гөнаһ шомлыгына каршы, ул сезгә бүләк алырга дип Казанга киткән иде, Рамил белән. Айныткычка эләккәннәр, имансызлар. Борчылмагыз, кадерлеләребез! Сафа Рафисов сезгә багышлап поэма язды. Район гәзитеннән укырсыз, чөнки ул кичә Ринат белән сугышып тешен сындырган. Сөйли алмый, "сез"не"шез-з"ди. Алга барабыз

— биеп алабыз. Кызлар башкаруында күмәк бию. Кызганычка каршы, Света көй язылган кассетаны югалткан. Теге бәйрәмдә биегәннәр иде. Шунда Гөлфинәнең итәге төшеп калды. Фәния белән Нурия дә жырлый алмыйлар. Дискотекада салкын

аракы эчкәннәр. Ә хәзер Илнар башкаруында "Алмагачлары" жыры. Кая соң ... кибет баскан диме... Кайгырмагыз юкка, кадерле әти-әниләребез, кадерле укытучыларыбыз.



Чиратта оригиналь номер, Дамир фокуслар күрсәтә! Әле генә монда иде бит. Концертыбыз ахырына якынлашып килә. Игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт сезгә, безнең кадерле әниләребез һәм хөрмәтле укытучыларыбыз. Киләсе бәйрәмдә сезне тагын концертыбызга көтеп калабыз!..




# Ташлау



## ТАШЛАУ

40 елдан соң! Җанашы моны көтмәгән иде.. Ничек инде? Гомере буе кулында гына йөртте. Үбеп кенә торды. Шулай бергә яшәгәннән соң. Юк, ышанмады. Ышана алмады.

Дөрес, ирнең әтисе дә, әнисе дә гел котыртып тордылар. Уллары аңа иялэшкәннән бирле "ташла ул кабахәтне" дип, бертуктаусыз әйтеп килделәр. Әмма ир турылыклы булды. Коткыларга бирешмәде. Сөйгәненнән аерылмады. Туганнары да, ул юньсезне ташларга кушып, ирнең бертуктаусыз колак итен ашадылар. Ир барыбер буйсынмады. Торган саен аңа тартылды. Җаны-тәне белән аны сөйде. Уенда гел-ул.гына булды. Беркайчан аңа хыянәт итмәде. Кая ул! Бу турыда хәтта уйларга да курыкты.' Аның.өчен үзен дә, акчасын да җәлләмәде. Рәхәт иде иргә аның белән бергә үткәргән " мизгелләр. Ай рәхәт, ләззәтле иде. Аның исләреннән үк ирнең башлары әйләнә иде. Менә шулай яшәделәр. Үлгәнче аерылышасы түгелләр иде. Ләкин көтмәгәндә иргә инфаркт булды. Йөрәк беткән, үпкә телгәләнгән. Кырык ел аның белән бергә яшәвенең нәтиҗәсе диделәр. Ир ыңгырашты. Сөйгәне белән аерылышу минутларын күз алдына китерде. Йөрәк чыгардай булып. тибә. Аяклар гөбедәй шешкән. Чырай балавыз кебек сап-сары иде. Ир сыкранып яшьлеген исенә төшерде. Үкенеч тойгысы бәгырен телгәләде. Ул нурсыз күзләре белән тирә-якка карады. Кеше-кара юклыгын күргәч, кесәсеннән тәмәке алып, авызына капты. Калтыранган кулары белән шырпы кабызды. Тирән итеп бер суырды.... һәм шапылдап ишек алды туфрагына килеп төште. Әгәр ир аңын җуеп егылмаган булса, аның кулыннан кырык ел буе төшмәгән тәмәке төпчеге әле һаман янар иде. Бетте рәхәт тормыш,-сүнде, сүрелде. Ни кызганыч! Иң кадерле нәрсәләрне гомер чигендә булса да ташларга туры килә икән ул.



# ДӘРЕС

**(монолог)**

Утырыгыз! Укып килдегезме? Галиев, бас! Сөйлә. Надан! Утыр, "ике"ле! Сәүбанов, яп китабыңны! Өйдә укырга кирәк. "Ике"ле! Рамазанов, җавап бир! Аңламадың? Ахмак! Ниязов, сөйлә әйдә. Мыгырданма, кәлүш авыз! Туры бас. Оһо,монда синең рәттән өч "ике"ле икән инде. Туфта сөйләмә. Базарыңны туктат! Юкса, тагын бер "ике"ле манчырмын! Ильясова, чык монда! Сөйлә. Нигә елыйсың? Әниең авырса, мин бит врач түгел. Укытучы! Дәрестән соң калып сөйләрсең. Дәүләтов! Саңгырау тәре. Дәүләтов дим! Плеерыңны алып башыңа бирәм бит хәзер! Чыгып кит класстан! Күземә күренмә. Бәрәңге ашый белмәгән авызың белән "рәхмәт" дип торасың тагы. Уф! Кабергә кертәсез бугай инде. Ачыгыз китапларны. Утыз беренче параграфны! Укыгыз! Сәүбанов, ач китабыңны! Карта салып утырма. Тагын бер кат укы. Ниязов, чык такта янына! Сөйлә. Истә калмады? Тавык мие.эчкән нәрсә!... Дәфтәрләрне алыгыз. Күчереп языгыз текстны. Вәлиев, укы дәфтәреңнән. Ничек танымыйсың? Идиот! Утыр, "ике"-ле! Ниязов, бәлки сөйләрсең. Нәрсәне? Атаң башын! Күктән төштең мәллә, йокы чүлмәге. Тавыш! Дежурный, такта сөртелмәгән. Шартлатып "ике"-ле куярмын! Табарсың аннан чүпрәгеңне. Бур кайда? Кичә ничәсе иде? Аңгыраерсың шул... сез аңгыралар белән. Минем шикелле 6 сәгать укытып карагыз...




Аннан ыржаерсың. Чык әле монда. Ал китабыңны. Кычкырып укы. Тыңлагыз! Аңлашылдымы? Сөйлә, Вәлиев! Син нәрсә укыдың? Чүбек баш, иртәгә укыйсы теманы укыгансың бит. Утыр, "ике"ле! Шыңшыма, монысы иртәгәсе өчен булыр. Барыбер укып килмисең. Гаттарова, мыштым гына нишләп утырасың анда? Секс-мексларны өйдә укыйбыз, яме? Кая, бир әле монда. Уһу!-Ай-яй... Конфискую журналыңны, иртәгә алырсың. Чү, звонок булды түгелме? Ишек шакыйлармы? Кайсыгызның әнисе килгән? Апа, җаным, кая керәсең, дәрес бит бу. Кичә акча алдыгыз дип, бүген класска сатарга трусик күтәреп кермиләр бит инде. Шауламагыз! Өй эшен языгыз. Иртәгә унар сум акча алып килергә. Завуч апагызның туган көне. Киләсе дәрескә тагын хәзерләнмичә килеп карагыз! Тирегезне тунармын, пычаксыз суярмын. Күр-сәтермен мин сезгә ничек укырга кирәклеген...

# БЕЗ КЕМНӘН КИМ?


Безнең авылда гел урлашып кына торалар, нәкъ Мәскәүдәге кебек, билләһи! Әле менә узган җомгада алыпсатар Галәү кибетен бастылар: өч кильки консервысы, ун күкәй һәм җиде "Чистай" аракысы алып чыгып киткәннәр. Бер көтү' милиция көне буе эзләде, һы, тотарсың алай гына! Өч көн үткәч үзләре каптылар. Шешә тапшырып тәмәке алырга торганда. Теге "Чистай" аракысы Галәү кибетендә генә булган икән.Ял көне сельпо складына керделәр. Түбә калаен куптарып,'өстән төшкәннәр. Складтагы бердәнбер диванны түбәгә күтәрә алмагач, пычкы белән стенаны кискәннәр. Милиция ике көн эзләде. Тотарсың безнекеләрне! Өч көннән соң диван үзе табылды. Склад мөдире "хәлен белергә" кибетче хатын янына кергән булган. Йомшак диванны капшап ята торгач утны кабызган бу. Ни күрсен - үз диваны. Кибетче хатын кемнәр китергәнен бәйнә-бәйнә сөйләп биргән.

Сишәмбедә авыл Советына керделәр. Галәмәт зур сейфны икенче каттан сөйрәп төшкәннәр. Якындагы бакчага алып барып, ишеген динамит белән шартлатып ачканнар. Әмма дә ләкин сейф буш булып чыккан. Дөрес, милиция дүрт муен тапкан: өчесе "Столичный"ныкы, берсе чит ил шешәсенеке. Шуңа ачу итеп микән, караклар "Патлы!" дип язып киткәннәр. Башлангыч сыйныф укытучысы Мәрьям апа шундук белгән кем язганын. Алып киттеләр, билгеле, тегеләрне.

Колхоз персиятеле шимбә, көн Казаннан кайтып килә икән. Саунага йөри ул, теге... кызлар массаж ясый торганына. Кәеф шәп моның. Ферма янында сыер суеп яткан егетләргә елмаеп, кул изәп китә. Тегеләр дә пычакларын болгап калалар. Кичен ферма мөдиренә чылтырата персиятел: "Бүтәкм өчпочмак тансыклап тора. Көндез суйган сыер итен җибәр әле әзрәк, хәйран гына итеп",-ди.— Ит юк бит, иптәш персиятел, — ди мөдир.— Ничек? — ди хуҗа. Шуннан, матур сүзләр белән аналарының хәлләрен белешкәннән соң, икесенең дә башына китереп суга. Шундук милициягә чылтыраталар. Тегеләр тагын өерләре белән килеп төшәләр. Китә эзләну, китә иснәнү. Дүрт тояк табып алалар. Сыерның суелып урлануы фактлар белән раслана. Дүрт көн үткәч базарга сөт сатарга барган Хания түти ит рәтендә яткан сыер башын танып ала. Ничек танымаска, колхоз өчен өч литрын биргәч, Хания түтине көн аралаш базарда сатарлык сөт белән тәэмин итеп торган сыер була бит ул.

Кичә мәчетнең сәдака яшнеген дә ватып караганнар иде. Тик акчасы булмаган. Хәзер авыл егетләре мәчеткә сәдака бирегез дип үзләре халыкны әгитләп йөриләр. Кемнең тик торганда буш яшнекне ватасы килсен ди инде. Ярый, сәдака салып кайтыйм әле. Я бирмәгәнне сизеп алырлар. езнең авыл егетләре бик гаярь, Аллам

сакласын.



# Чир

Көтмәгәндә-уйламаганда

Галәвинең дәү корсагында кечкенә генә кызыл тап пәйда булды. Хатыны сыер җилеменә сөртә торган май биреп карады — бетмәде кызыл тап.

Иртәгесен иртүк Галәви корсагын күрсәтергә күрше карчыгына керде. Карчык озын-озак дога укып, олы корсакка шактый гына төкерек чәчте. Әмма теге тап өшкерүне төчкереп тә бирмәде.

Галәви, корсагын тотып, фельдшер кызга йөгерде. "СПИД" гәзитеукып утырган яшь кызның шәлперәйгән корсакка әллә ни исе китмәде. Шешә төбеннән чыра белән каезлап алып чиргә яшел дару сөртте. "Тагын кирәк булса, эптиктән алырсың. Миндә бүтән юк", — дип кырт кисте.

Тап икенче көнне дә юкка чыкмады. Галәви, җанын учына кысып, районга чыгып китте. Юлда очраган танышларына, авыр сулап: "Әптик юлын таптыйм", — дип җавап бирде. Дару хәйран кыйммәт иде. Галәвинең автобус белән авылга кире кайтырлык акчасы калмады. Әле ярый укытучы Азат очрап, шуннан унсигез сум әҗәткә алды.

Өенә кайтып керүгә Галәви ухылдап караватка ауды. Хатынына үзе алып кайткан сыек даруны сөрхәл булмагае дип, район сырхауханәсенә илтергә ниятләделәр. Монда табиблар корсакны бик җентекләп карадылар. Соңыннан үзара чыш-пыш сөйләшеп алдылар. Галәвинең җаны табанына төште: "Чирем яман икән. Бик озак сөйләштеләр", — дип уйлады ул. Аңа өч төрле дару язып бирделәр. Икесен эчәргә, берсен иртә-кич тапка сөртергә куштылар.

Икенче көнне, идән астыннан алты капчык бәрәңге тутырып, кибеткә илттеләр. Дару алырга акча кирәк иде. Шулай итеп, Галәви чын хастага әйләнде. Иртән уянуга корсагын капшый. Сыпыргалап сасы дару сөртә. Озаклап, бөтен шартын китереп, ике төймә дару эча. Юынмый, кырынмый, сөйләшми.

Галәви чирле икән дигән хәбәр бөтен авылга таралды. Хастаның хәлен белергә күрше-тирә керә башлады. Кергән берсе Галәвине кызгана, юата, тегеләй-болай итеп карарга киңәш бирә. Түшәм ярыгына карап яткан Галәвине аның саен шомлырак уйлар биләп ала. Күзләреннән мөлдерәп яшьләр чыга.

Шулай итеп атна узды. Чир чигенмәде. Авыру кешене әйбәт ашатырга кирәк дигәч, көтүдән кайтмый йөдәткән тәкәне суйдылар. Тагын алты капчык бәрәңге

тутырдылар. Бу акчага хатыны колбаса, консервы, өрек, вак җимеш, кара җимеш,

әфлисун, карбыз, банан, кәнфит, прәннек

ише нәрсәләр алып кайтты. Галәвинең

һәр ашавына мулдан ит белән бәрәңге, майлы шулпа, кыстыбый я өчпочмак булды. Ул һәрвакыт коймак белән өрекле чәй эчеп, ахырдан әфлисун яки банан ашап куярга гадәтләнде. Мондый затлы вә тәртипле ашауны күрмәгән корсак хәйран зурайды. Корсак белән бергә теге тап та зурайды.

Эчкән, сөрткән даруларның файдасы

тимәгәч, Галәви телевизордан күрсәткән чит ил даруларын алып карарга кирәк дигән фикергә килде. Тагын бер сарыкны суеп саттылар. Чит ил дарулары белән дәвалану башланды. "Галәви герман даруы эчә икән", — дигән хәбәр бөтен авылны шаулатты. Кайберәүләр: "Болай булгач беткән икән мескен", — дип чын күңелдән кызгандылар.

Галәви Казанга барып карарга булды. Баҗасы зур бер түрәне йөртә иде. Шуның аша сырхауханәгә урнашты. Өйгә.газ кертергә дип үстергән тананы суйдылар. Акчасы даруларга һәм хатынга юл йөрергә китеп бетте. Көн дә эштә була алмагач, хатынны эшеннән чыгардылар.

Беркөнне Галәви йокысыннан иртәрәк уянды. Гадәт буенча корсагын капшап карады. Чирне сыйпау, тоткалап карау көндәлек эшкә әйләнгән иде. Бу юлы коты очты. Урыныннан сикереп торды. Каушады. Майкасын күтәреп тиз-тиз корсактан чирен эзләде. Юк чир! Эзе дә калмаган. Галәвинең маңгаена бөрчек-бөрчек салкын тир бәреп чыкты. Күз аллары караңгыланды. Күпме тәрбияләп,


күпме дәвалаган, күпме акча түккән чир кая китәргә мөмкин? Ул бу чиренә тәмам иялəнгән иде.Аңа ачуы да чыкмый башлаган иде инде. Җитмәсә, хатыны бүген долларга сатып алган Америка даруы алып кайтырга тиеш. Аны профессор караячак иде. Ә чир юк! Юк чир. Нишләргә? Унике капчык бәрәңге, бер тәкә, бер сарык, кыш чыккан тана һәм исәпсез тавык-чебеш, казүрдәк бәһәсенә тиң чир шулай көтмәгәндә юкка чыксын әле. Бу хәлгә ничек түзәргә кирәк?!

Табиблар кергәндә Галәви һушсыз булып караватында ята иде. Врачлар йөрәгенә кан сауган дигән диагноз куйдылар.



# КҮТӘРЕЛЕШТӘ

www.vafin.mugallim.com



Калхузны кем таратып бетерде? Укытучылар! Элек мәктәп директоры җәй буе ыштан төбен салындырып чөгендер чүбе утап ята иде. Бәрәңге дә басуда калмый иде. Үктәбер бәйрәмнәре җитмичә укытучылар мәктәпкә әйләнеп тә бакмадылар. Кая кушсалар, шунда йөгерәләр иде. Иген урдылар, борчак чаптылар, ашлык киптерделәр, агач утырттылар, урам баганаларын агарттылар, юл кырыйларын чүптән чистарттылар, куян үрчеттеләр, яшелчә үстерделәр, лозунглар язып элДеләр. Балалар да гыйлемле иде. Шул заманда райком секретаре басуларны карап йөри икән: Аңа Пеләш Сәйфинең кече малае, кырда мең ике йөз башак калса, биш центнер ашлык җыела дип исәпләп биргән. Куркуыннан математика укытучысы Рәхим абыйга шундук инфаркт булып җиргә егылган.

Җәйге ялларында да укытучылар хәзерге шикелле бот күтәреп өйләрендә ятмадылар. Балта кыстырып яфрак җыярга китәләр иде. Елга буйла-' рында печән чаптылар.. Җыр укытучысы Хәния апа, йөк өстеннән егылып, умыртка сөяген сындырган елны


Хәзер җыймыйлар. Сыерлар коры салам ашый. Шуңа күрә иттә юк, сөттә юк.

Кышның-кыш буе укытучыларның фермадан башлары чыкмый иде. Дәресләре бетүгә гөҗи--журналлар күтәреп фермага чабалар иде Мескеннәр. Пычрак сыерларга кадәр юалар иде. Шәһәрдән кайткан немец теле укытучысы Лениза үгезне юа башлаган бит шулай беркөнне. Пләмән үгез сөзгән дә еккан, тегене. Кабыргалары сынып беткән иде. Ленизаның, билгеле.

Әйе... Сагынып сөйләргә генә калды. Кара син бүгенге укытучыларны. Уч тутырып акча алып тик яталар. Элек аларның бәйрәмнәрдә куйган концерт-театрларын еллар буе онытмый идек. Тарих укытучысы Сәлим абый "Галиябану"ны куйганда тәрәзәдән егылып төшеп башын тиште. Шул тишек башы белән булса да уйнап бетерде. Хәзер шәһәрдән килгән артист калхузның соңгы тиеннәрен сыпырып китә. Укытучы залда авызын ерып, кәмит карап утыргач, калхуз баемый, билгеле.

Дөрес микән, юк микән — күрше калхузда укытучыларга бирәр гектар чөгендер бүлеп биргәннәр дип ишеттем әле. Мәктәпләрдә бозау, дуңгыз асрарга кушалар ди. Районда үткәрелүче ярминкәләрдә укытучыларны биетә башлаганнар. Болайга китсә, иске эзгә төшсәк, акрынлап тернәкләнербез, Алла боерса.

# ТӘҖРИБӘ ҖИМЕШЕ



Сәлимнең дәресенә мәктәпнең укыту бүлеге мөдире керде. Яшь егетнең институт бетереп кайтып, укыта гына башлаган көннәре иде.

— Менә болай, энем, - диде завуч кызыл борынына ватык пыялалы күзлеген элеп. — Ярыйсы гына болай дәресең. Сөйләвең начар түгел. Тик син көн яңалыкларын өстәргә онытма. Террор, шартлаулар... Татар балалары татарчаны и так беләләр. Нокталар, өтерләрең беркая да качмас.

Берәр атна үткәч, методик берләшмә җитәкчесе Сәлимнән дәрескә керергә рөхсәт сорады. "Кушалар бит", — диде ул директор бүлмәсенә ишарәләп. Бу яшь, чибәр кыз икенче елын эшли. Оялчан нәрсә кебек күренсә дә, дәрестән чыккач кыз Сәлимнең дәресенә завучтан да болайрак анализ ясап ташлады. Өстәвенә, татар телен инглиз теле белән бәйләргә киңәш итте..

Көннәрдән бер көнне дәрескә мәктәп директоры үзе килеп керде. Дәрес башланып ун минут үткән иде инде. Менә ишек ачылды һәм йомры пеләш баш күренде.

—6нчы а мы? — дип сорады ул

—7а, — диде Сәлим.

—6 нчы түгелмени? Йә, ярар, бигрәк әйбәт, — дип мыгыр-дана-мыгырдана-директор арттагы буш урынга барып утырды.- Дәвам ит, энем, дәвам ит. Дәреснең һәр минуты кадерле.

Сәлим аналитик иярчен җөмләләрдә өтер кую очраклары турында сөйли иде.

Директор бераз утыргач, урыныннан торып, укучыларның дәфтәрләрен карап чыкты, җылыту торбаларына кулын тидереп чыкты,тәрәзә төбендәге гөлләрне тикшерде,бүлмәсенә барып телефоннан сөйләшеп килде.

Дәрескә анализ директор бүлмәсендә үтте.

—Дәресең дәрес шикелле болай үзе, — дип башлады директор. — Ну, техник чаралар күрмәдем: магнитофон, кодоскоп, диапроектор: Берәр таблица элсәң дә мишәйт итмәс иде.Такта чүпрәгеңне алыштыр. Аналитик җөмләләрне өйрәткәндә алгебра белән бәйләсәң шәп буласы иде. Җөмләне яза инде алар, ә менә математикалары, ай начар!..

Әкренләп Сәлимнең дәресенә башка укытучылар да керә башладылар. Мәктәптә үзара тәҗрибә алмашу кирәк дип,укытучыларны бер-берсенең дәресенә керергә мәҗбүр итәләр. Күп нәрсәгә өйрәттеләр алар Сәлимне. Рус теле укытучысы дәрестә рус язучыларын әйтмичә калдырырга һич ярамый диде. Химия укытучысы реакциягә

басым ясарга кирәклеген искәртте. Җыр укытучысы берәр җыр яңгыратып алсаң нур өстенә нур өстәлер иде диде. Биолог дәрескә җәнлек алып керергә кушты.



Уку елы ахырында мәктәпкә район мәгариф бүлегеннән тикшерүчеләр килеп төште. Сәлимнең дәресен бик мактадылар. Хәтта башкаларга үрнәк итеп күрсәттеләр. Чөнки "җөмлә""темасын өйрәткәндә Сәлим Америкадагы шартлаулар, бездәге чыпчыклар, Джек Лондон романнары турында сөйләде. Укучылар колхоз басуында ашламалар кулланcаң бодайның күпме уңыш бирүен

исәпләделәр. Куштылар, алдылар, җырладылар, физкультура күнегүләре ясадылар. Сәлим мәктәп бакчасыннан кисеп бер алмагач кертеп куйган иде. Ботагына Пушкин әкиятендәгечә чылбырлап күрше әбинең мәчесен менгереп утыртты. Шуңа багышлап 'Алма агачы бакчада үсә" дигән җөмләне тактага язып куйды. Бу җөмләне инглизчә магнитофоннан тыңлатты. Тикшерүчеләр тактадагы язуны бик ошаттылар.Бик матур язылган диделәр.




Икенче уку елы алдыннан Сәлимнең авыз ерып төшкән рәсеме район мәгариф бүлегенең Мактау тактасында эленеп тора иде.




# “Әнәскә бар!”

Шакир арып-талып эштән кайтты. Кәефе юк, җитмәсә бер теше дә сызлап тора. Ишектә ат башы кадәр йозакны күргәч, бөтенләй кешелектән чыкты. Ул ачкыч алыйм дип баскыч астына үрелде һәм... кулына килеп эләккән аракы шешәсен тартып чыгарды. Нәкъ шулвакыт ярымаек күршесе Әнәс килеп керде.

Билгеле инде, шешә ачылды. Берәрне каплап куйгач, сүз Шакирның сызлаган черек тешенә күчте. Әнәс кинәт кенә торып, өенә чыгып китте дә, канистр белән керосин күтәреп керде. Ишегалдында яткан табакка керосин салып, Шакирга аягын шунда тыгып утырырга кушты. Ахылдап-ухылдап, тагын берәрне тотып куйдылар. Сүз әллә кая ерак китә алмыйча, тагын черек тешкә килеп төртелде. Сызлавы болай гына басылмагач, Әнәс күршесенә керосинны бераз авызына кабып торырга киңәш итте. Хуҗа шулай эшләде. Ул арада Әнәс үзе генә тагын берне каплап куйды.

Шакирның да үтереп тартасы килде. Керосинны төкереп ташлап, авызына сигарет капты. Әнәснең шырпы сызып Шакирга якын китерүе булды – авыз тирәсендә бүрек кадәр ут күтәрелде. Каушавыннан Шакир чәбәләнә башлады. Ут табакка төште. Шакирның аяк асты

дөрләп янарга тотынды. Әнәс: “Каравыл! Янабыз!” – дип, акыра-бакыра йөгереп чыгып китте. Ә Шакир тиз генә урамга чыгып, колонкадан су агызып, чалбар балакларына үрмәләгән утны сүндерде дә, битен-башын юып, кире керде. Шешәдә калган “шайтан суы”н йотып бетерде. Менә бәхет, сызлаган теш бөтенләй онытылды бит! Шулай кәефләнеп, койма кырыендагы чирәмдә утырганда янгын сүндерү машинасының чинаганы ишетелде. Эшне аңлап алган Шакир тиз генә бакча артлатып, болынлыкка сызды.

Соңыннан шул ачыкланды: Әнәснең хатыны күршесенә әҗәтен керткән икән, ә ишектә йозак. Кире алып чыгасы килмичә, Әнәс күрер дип, ул шешәне баскыч астына яшергән. Гөнаһ шомлыгына каршы, бу көнне Шакир эштән иртәрәк кайткан.

Шушы хәлдән соң авылда теше сызлап интеккән кешегә: “Әнәскә бар!” – ди башлыйлар.

# Уйлар.

Хатын-кыз эндәшмәсә, аны бүлдермәвең хәерлерәк.

Хатын-кыз ир кешедә аны чишендерү теләге тусын өчен киенә.

Башың авыртса, шатлан, димәк, ул урынында.

Руль артындагы хатын күктәге йолдыз кебек. Син аны күрәсең, ә ул сине юк.

Салымыңны түлә дә тынычлап йокла: вокзалда, подвалда, урамда...




# Барасы *килә.*

## БАРАСЫ КИЛӘ

Их барасы килә! Тик алмыйлар да алмыйл-
ларКая булсын, армиягә инде! Акчаны аз
азрак торттем ахрысы. Язгы чакырылыш
вакытында күбрәк бирәсе булыр, чөнки б
ар бар асы бик тә килә. Шунда бар ып ,
шлай ашап, бушлай кие неп йөр ис е
лә. Монда барыбер акча юк. Эшк ә а
ыйлар. Дипломың үзеңә булсын, безгә ПТ
бетереп кил диләр.

Врачлары да бик надан. Авызында ике тешең юк икән, “ак билет” бирәләр. Солдат шулпасын чөмерергә теш кирәкмени, тинтәкләр? Анда кул кирәк. Идән юу өчен, офицерларны сәламләү өчен, командирларга йорт төзү өчен.

Ничек кенә китәргә бу армиягә? Генералга язып карыйм микән әллә? Минем дә бит тузган кәчтүмне ташлап, Юдашкин теккән модный мундирлар киеп йөрисем килә. Әле бушлай телефон да бирәләр ди. Менә рәхәт тормыш, ә! Бушлай киенеп, бушлай сөйләшеп ят әле.

Китәм булгач, китәм. Тәмам туйдырды. Иртән торып күзне ачуга акча сорый башлыйлар. Мондый эт тормышында яшәгәнче, Русия армиясендә солдат булуың мең артык. Манный боткасын сыпыртып куясың да, ятасың казармада түшәмгә төкереп. Уйлыйсы юк, эшлисе юк. Аратирә чокыр казып, койма буяп кайтасың да, шуның белән вәссәлам.

Берәр олигарх йә банкир малае булсам, күптән алырлар иде инде. Укытучы малае

булгач, алмыйлар шул, кешегә санамыйлар.

Их, ничекләр генә итеп армиягә эләгәсе? Ничек кенә бушлай ашап, бушлай киенеп яшисе?

# Уйлар

Чын хатын агач кисәргә, өй җимерергә һәм кыз үстерергә тиеш.

Сәбәпсез көлгән кеше – йә дивана, йә чибәр кыз.

Кешелек кайчан да булса склероз, маразм һәм инфаркт дигән сүзләрне онытачак, чөнки врачлар тырышлыгы белән кешеләр яшь һәм сәламәт килеш үләчәкләр.

Тәмуг – бу безнең тормыш һәм, өстәвенә, аракысыз тормыш.

Оҗмах – инглиз өе, кытай кухнясы, марҗа хатыны һәм американнар алган хезмәт хакы.

Бер куян артыннан чабып, икене тотып булмый.

Сакаллы булу – акыллы булу дигән сүз түгел, ышанмасаң, кәҗәгә кара.

Әҗәткә акча бирү – хәтерне яхшырта.

Бөтен хатыннар да яшь, әмма кайберләре бөтенләй яшь.

Кешеләр беркайчан да үлмәс кебек яшиләр һәм беркайчан да яшәмәгән кебек үлеп тә китәләр.

Дөреслек шул – ул юк.

Йөз дустың булганчы йөз мецең булсачы.

# Табышмак.

**ТАБЫШМАК**




2нче сыйныф.Татар теле дәресе.Гади дәрес түгел,район укытучылары кереп утырган ачык дәрес.Дәрес бетүгә бара. Укучылар өйдә табышмаклар өйрәнеп килергә тиеш булганнар.Укытучы шуларны сорый башлады.Беренче булып алгы партада утырган күзлекле кыз торып басты.Сакаулап үзе әзерләп килгән табышмагын әйтте.

-Ике кылыеннан тотасын да ултасына тыгасың.Ул нәлсә?

Әле быел гына укыта башлаган яшь укытучы кызның битенә алсулык йөгерде.Арткы рәттән бер малай кычкырды: -Апа,моны миңа эти өйрәткән иде.Әйтимме?

-Әйтеп кара,-диде укытучы еш-еш сулыш алып.

-Носки кию ул,апа,-диде малай шар ярып.-Үземнекен әйтимме?

Укытучы өлгергәнче,малай әйтеп тә салды: -Сыерда дүртәү,апада икәү.

Аннан үзе янында утырган кызга карап өстәде: -Саниядә дә икәү.

Укытучы тагын кызарды.Укытучылар идән ярыкларын саный башладылар.

Сания дигәне сикереп торды: -Апа,моның җавабы бик җиңел.Аяклар ул.Менә минекен бирәү дә белим. “К”га башлана,“К”га бетә.Уртасында “Т” хәрефе.

Укытучы бөгелеп төште.Укытучылар арасында утырган директор тиз генә торып класстан чыгып китте.

-Мин беләм,мин беләм,-диештеләр балалар.Укытучы кайсыннан сорарга белмәде.Шунда бер малай түзмәде: -Кәтүк җебе.Кәтүк,кәтүк,-дип кычкырды.

Укытучылар елмаешып куйдылар.Тагын куллар күтәрелде.Берсе алга ук йөгереп чыкты.

-Кичә әни табышмаклар китабы алып кайтты.Шуннан өйрәнеп килдем.

Укытучы куанып, укучының аркасыннан сөеп куйды.

-Тыңлыйм,акыллым.Әйдә әйтеп җибәр әле.

-Уртасы дымлы...дымлы, ике кырые җонлы...җонлы,ачыла да ябыла,ачыла да ябыла.

Завуч кыбырсынып куйды.Укытучылар алларындагы дәфтәрләрен бер ачтылар,бер яптылар.

Куллар күтәрелде

-Үзем әйтәм,-диде моңарчы кушылмаган малай ,акрын гына торып басып.-Беләм ,әбидән ишеткән идем.

(Үле тынлык урнашты.Завуч сәгатенә карап,тиз генә класстан чыгып китте).

-Күзләр ул ,апа,күзләр.

Укытучылар куанып бер-берсенә караштылар.Ул арада “мин әйтәм”дә “мин әйтәм” дип балалар укытучы кызны чолгап алдылар.Звонок яңгырады.Укытучылар берсен-берсе узып,ишеккә ташландылар.